**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

28.12.2018 1397-п

**Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Казансу елгасының һәм аның кушылдыклары: Сухая, Кесмәс, Нөксә, Киндерле, Солонка, Шимяковка, Кырлай, Красная, Аты, Каменка, Бирәзә, Ия, Каймарка, Сөлә елгаларының һәм 4 исемсез кушылдыкның яр буе линияләре урнашкан урынын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Су кодексының 26, 65 статьялары, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы федераль законның 32 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» федераль законның 32 статьясының 1, 3-13, 15 өлешләре нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан дәүләт кадастр исәбен, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып баруга һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләрне бирүгә вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына (аның территориаль органнарына) җибәрелә яки тапшырыла торган документларны тапшыру кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 31 декабрендәге 1532 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яр буе линияләренең (су объекты чикләрен) урнашкан урыннарны, аны билгеләү очракларын һәм ешлыгын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында һәм Җирлектә су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе яклагыч полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 29 апрелендәге 377 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлектә су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе яклагыч полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 10 гыйнварындагы 17 номерлы карары, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Федераль мөлкәттә торучы һәм Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан су объектларын яки аларның өлешләрен саклау чараларын гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашыру буенча методик күрсәтмәләр

раслау турында» 2010 елның 29 сентябрендәге 425 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары, «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының: Казансу елгасының һәм аның кушылдыкларының (Сухая, Кесмәс, Нөксә, Киндерле, Солонка, Шимяковка, Кырлай, Красная, Аты, Каменка, Бирәзә, Ия, Каймарка, Сөлә елгаларының һәм 4 исемсез кушылдыкның) су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе яклагыч полосалары чикләрен билгеләү» 2018 елның 17 июлендәге 18МЭ-13с дәүләт контракты кысаларында башкарылган эшләрнең нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы буенча 2018 елда су мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең аерым вәкаләтләрен Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акча хисабына финанслана торган һәм максатчан фараз күрсәткечләренә ирешүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеге нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Казансу елгасының һәм аның кушылдыклары: Кесмәс, Нөксә, Киндерле, Солонка, Шимяковка, Кырлай, Красная, Аты, Каменка, Бирәзә, Ия, Каймарка, Сөлә елгаларының һәм 4 исемсез кушылдыкның (Биектау муниципаль районының Иске Бөреле, Яңа Бөреле, «Бөреле» совхозы поселогы торак пунктлары районындагы тамаклар - 2 кушылдыкның) яр буе линияләре урнашкан урынны (су объектлары чикләрен) билгеләргә.
2. Су объектларын саклау бүлегенә (Д.Р. Вилданова) материалларны билгеләнгән тәртиптә дәүләт су реестрына кертү өчен Су ресурсларының федераль агентлыгына җибәрергә.
3. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.Е.Никулин) әлеге боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.
4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары Р.И. Камаловны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.В. Шадриков